**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 апреля 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 11 (I часть); 2015, № 12 (I часть); 2016, № 1 – 2, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 33 (часть I), № 94 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 2:
а) в части 4 слова «двух календарных месяцев» заменить словами «трех календарных месяцев»;
б) в части $4^1$ слова «пяти календарных месяцев» заменить словами «шести календарных месяцев»;

2) часть 1 статьи 3:
а) дополнить пунктом $13^7$ следующего содержания:
«$13^7$) определение порядка информирования органами местного самоуправления собственников помещений в многоквартирных домах о способах формирования фонда капитального ремонта, о порядке выбора способа формирования фонда капитального ремонта;»;
б) дополнить пунктом $13^8$ следующего содержания:
«$13^8$) установление порядка информирования собственников помещений в многоквартирных домах и организаций, осуществляющих управление

многоквартирными домами, о содержании региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах и критериях оценки состояния многоквартирных домов, на основании которых определяется очередность проведения капитального ремонта;»;

в) дополнить пунктом $13^9$ следующего содержания:

«$13^9$) утверждение порядка и перечня случаев оказания на возвратной и (или) безвозвратной основе за счет средств бюджета Республики Татарстан дополнительной помощи при возникновении неотложной необходимости в проведении капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах;»;

г) дополнить пунктом $13^{10}$ следующего содержания:

«$13^{10}$) установление порядка информирования собственников помещений в многоквартирных домах об исполнении органом государственной власти или органом местного самоуправления, уполномоченными на дату приватизации первого жилого помещения в многоквартирном доме выступать соответственно от имени Российской Федерации, Республики Татарстан, муниципального образования в качестве собственника жилого помещения государственного или муниципального жилищного фонда, являвшимися наймодателем (далее также – бывший наймодатель), обязанности по проведению капитального ремонта общего имущества в многоквартирном доме, а также о положениях части 4 статьи $190^1$ Жилищного кодекса Российской Федерации;»;

д) дополнить пунктом $13^{11}$ следующего содержания:

«$13^{11}$) установление порядка определения бывшим наймодателем перечня услуг и (или) работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирном доме, которые требовалось провести на дату приватизации первого жилого помещения в таком доме в соответствии с нормами содержания, эксплуатации и ремонта жилищного фонда, действовавшими на указанную дату;»;

3) в пункте 3 статьи 4 слова «и предложениями регионального оператора» исключить;

4) в части $6^2$ статьи 5 слова «установленным частью 2 статьи 176 Жилищного кодекса Российской Федерации, а также требованиям,» исключить;

5) часть 1 статьи 8 изложить в следующей редакции:

«1. Перечень услуг и (или) работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирном доме, оказание и (или) выполнение которых финансируются за счет средств фонда капитального ремонта, который сформирован исходя из минимального размера взноса на капитальный ремонт, установленного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан, определяется в соответствии с Жилищным кодексом Российской Федерации. Указанный перечень услуг и (или) работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирном доме постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан может быть дополнен услугами и (или) работами по утеплению фасада, переустройству невентилируемой крыши на вентилируемую крышу, устройству

выходов на кровлю, установке автоматизированных информационно-измерительных систем учета потребления коммунальных ресурсов и коммунальных услуг, установке коллективных (общедомовых) приборов учета потребления ресурсов, необходимых для предоставления коммунальных услуг, и узлов управления и регулирования потребления этих ресурсов (тепловой энергии, горячей и холодной воды, электрической энергии, газа) и другими видами услуг и (или) работ.»;

6) в части 2 статьи 9 слова «, настоящим Законом» заменить словами «и постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан»;

7) дополнить статьей $9^1$ следующего содержания:

«Статья $9^1$. **Минимальный размер фондов капитального ремонта в отношении многоквартирных домов, собственники помещений в которых формируют фонды капитального ремонта на специальных счетах**

Минимальный размер фондов капитального ремонта в отношении многоквартирных домов, собственники помещений в которых формируют указанные фонды на специальных счетах, составляет пятьдесят процентов оценочной стоимости капитального ремонта многоквартирного дома, определенной в соответствии с методическими рекомендациями, утвержденными уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти.»;

8) часть 10 статьи 10 дополнить пунктом 5 следующего содержания:

«5) внесение в региональную программу капитального ремонта изменений обусловлено изменением сроков проведения работ по ремонту внутридомовых инженерных систем газоснабжения, ремонту или замене лифтового оборудования, признанного непригодным для эксплуатации, в соответствии с требованиями части $3^1$ статьи 168 Жилищного кодекса Российской Федерации.»;

9) часть 2 статьи 11 изложить в следующей редакции:

«2. Региональной программой капитального ремонта в приоритетном порядке могут быть предусмотрены работы по ремонту внутридомовых инженерных систем газоснабжения, ремонту или замене лифтового оборудования, признанного непригодным для эксплуатации.»;

10) дополнить статьей $13^1$ следующего содержания:

«Статья $13^1$. **Финансирование за счет средств бюджета Республики Татарстан проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирном доме, в котором требовалось проведение капитального ремонта на дату приватизации первого жилого помещения**

1. Финансирование за счет средств бюджета Республики Татарстан оказания услуг и (или) выполнения работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирном доме, в котором требовалось проведение капитального ремонта на дату приватизации первого жилого помещения в таком доме, проводимому в соответствии со статьей $190^{1}$ Жилищного кодекса Российской Федерации органом государственной власти Республики Татарстан, уполномоченным на дату приватизации первого жилого помещения в многоквартирном доме выступать от имени Республики Татарстан в качестве собственника жилого помещения государственного жилищного фонда Республики Татарстан, являвшимся наймодателем, осуществляется путем предоставления субсидии региональному оператору или владельцу специального счета. Основанием для предоставления субсидии является включение многоквартирного дома в соответствии со сроком проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирном доме, определенным региональной программой капитального ремонта, в краткосрочный план реализации региональной программы капитального ремонта.

2. Предоставление региональному оператору или владельцу специального счета субсидии, указанной в части 1 настоящей статьи, осуществляется за счет средств, предусматриваемых в бюджете Республики Татарстан на государственную поддержку проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, включенных в краткосрочный план реализации региональной программы капитального ремонта.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан принять нормативные правовые акты, обеспечивающие реализацию настоящего Закона, в течение трех месяцев со дня вступления в силу настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
14 мая 2018 года
№ 30-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 4 өлештә «ике календарь ай» сүзләрен «өч календарь ай» сүзләренә алмаштырырга;

б) $4^1$ өлештә «биш календарь ай» сүзләрен «алты календарь ай» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $13^7$ пункт өстәргә:

«$13^7$) җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләренә капиталь ремонт фондын булдыру ысуллары турында, капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайлап алу тәртибе турында мәгълүмат бирү тәртибен билгеләү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^8$ пункт өстәргә:

«$13^8$) күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләренә һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаның эчтәлеге турында һәм күпфатирлы йортларның торышын бәяләү критерийлары турында, алар

нигезендә капиталь ремонт ясау чираты билгеләнә, мәгълүмат бирү тәртибен билгеләү;»;

в) түбәндәге эчтәлекле $13^9$ пункт өстәргә:

«$13^9$) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгәндә, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән кире кайтарыла торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибен һәм очраклар исемлеген раслау;»;

г) түбәндәге эчтәлекле $13^{10}$ пункт өстәргә:

«$13^{10}$) күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләренә күпфатирлы йортта беренче торак урынны хосусыйлаштыру датасына дәүләт яисә муниципаль торак фонды торак урыны милекчесе буларак наемга бирүче (алга таба шулай ук – элеккеге наемга бирүче) булып торган тиешенчә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек исеменнән эш йөртергә вәкаләтле булган дәүләт хакимияте органының яисә җирле үзидарә органының күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча бурычларны үтәве турында, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының $190^1$ статьясындагы 4 өлеше нигезләмәләре хакында мәгълүмат бирү тәртибен билгеләү;»;

д) түбәндәге эчтәлекле $13^{11}$ пункт өстәргә:

«$13^{11}$) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә мондый йортта беренче торак урынны хосусыйлаштыру датасына, шул датага гамәлдә булган торак фондны карап тоту, эксплуатацияләү һәм ремонтлау нормаларыннан чыгып, таләп ителгән капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеген элеккеге наемга бирүче тарафыннан төзү тәртибен билгеләү;»;

3) 4 статьяның 3 пунктында «һәм региональ оператор тәкъдимнәре» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 5 статьяның $6^2$ өлешендә «Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 8 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге, аларны күрсәтү һәм (яисә) башкару капиталь ремонтка кертемнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финанслана, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә билгеләнә. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең күрсәтелгән исемлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә фасадны җылыту, җилләнми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп үзгәртеп кору, түбәгә чыгу юлларын ясау, коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпләүнең кумәк (гомумйорт) җайланмаларын һәм әлеге ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) куллануга идарә итү һәм

аны җайга салу узелларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр, башка төр хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өстәлергә мөмкин.»;

6) 9 статьяның 2 өлешендә «, әлеге Законда» сүзләрен «һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында» сүзләренә алмаштырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле 9¹ статья өстәргә:

«9¹ статья. **Күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан махсус счетларда булдырыла торган капиталь ремонт фондларындагы күпфатирлы йортларга ясала торган капиталь ремонт фондлары минималь күләме**

Күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан махсус счетларда булдырыла торган капиталь ремонт фондларындагы күпфатирлы йортларга ясала торган капиталь ремонт фондлары минималь күләме күпфатирлы йортка капиталь ремонтның Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнгән бәяләү хакының илле процентын тәшкил итә.»;

8) 10 статьяның 10 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясының 3¹ өлеше нигезендә йорт эчендәге газ белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау, файдалану өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазын ремонтлау яисә алмаштыру эшләрен башкару срокларының үзгәртелүенә бәйле булса.»;

9) 11 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Капиталь ремонт буенча региональ программада, өстенлек бирелеп, йорт эчендәге газ белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау, файдалану өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазын ремонтлау яисә алмаштыру эшләрен башкару каралган булырга мөмкин.»;

10) түбәндәге эчтәлекле 13¹ статья өстәргә:

«13¹ статья. **Беренче торак урынны хосусыйлаштыру датасына капиталь ремонт ясау таләп ителгән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау**

1. Күпфатирлы йортта беренче торак урынны хосусыйлаштыру датасына капиталь ремонт ясау таләп ителгән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә Россия Федерациясе Торак кодексының 190¹ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды торак урыны милекчесе буларак наемга бирүче булып торган Татарстан Республикасы исеменнән эш йөртергә күпфатирлы йортта беренче торак урынны хосусыйлаштыру датасына вәкаләтле булган Татарстан Республикасы

дәүләт хакимияте органы тарафыннан ясала торган капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләр башкаруны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау региональ операторга яисә махсус счет иясенә субсидия бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Субсидия бирү өчен капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына, капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срогына туры китереп, күпфатирлы йортның кертелүе нигез булып тора.

2. Региональ операторга яисә махсус счет хуҗасына әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән субсидияне бирү Татарстан Республикасы бюджетында капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме өчен каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 30-ТРЗ